**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чалпы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чалпы авылы № 159 «26 » май 2025 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Советының 2018 елның 17 маендагы 101 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карары белән расланган (11.10.2018 №121, 28.11.2018 №125, 10.09.2020 №190, 17.10.2022 №76, 05.04.2023 №87, 07.06.2024 №131, 15.10.2024 №139 карарлар редакциясендә) Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләрне кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турындагы 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы» карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә

Чалпы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Советының 2018 елның 17 маендагы 101 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карары белән расланган (11.10.2018 №121, 28.11.2018

№125, 10.09.2020 №190, 17.10.2022 №76, 05.04.2023 №87, 07.06.2024 №131, 15.10.2024 №139 карарлар редакциясендә) Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«1.5. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары башкаручы кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләменә бермәбер исәпләнә, 15 389,00 сум тәшкил итә дип билгеләргә»;

б) 2.2 пунктта:

-икенче абзацта ике «10,36» санын «16,85» санына алмаштырырга;

- өченче абзацта «9,26» санын «15,48» санына алмаштырырга;

в) 3.2 пунктның 5 пунктчасында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга;

г) 3.3 пунктының 5 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга;

д) 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: А.М.Мөхәмәтшин

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Советы карарына кушымта
«26» май 2025 № 159

Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге башлыгы, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларның айлык акчалата түләү күләме

| Вазыйфаның исеме | Авыл җирлекләрендә | |
|---|---|---|
| | 11 төркем | 12 төркем |
| 1 | 2 | 3 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 23 091 | 21 091 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 16 594 | 15 391 |
| Депутатлар | 15 389 | 15 389 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 15 389 | 15 389 |